# “Баш иябез Бөек елларга”

# 1941-1945

## Бөек Ватан сугышы елларындагы сугыш чоры балалары турында хәтер альбомы

**Сабабаш авылы буенча**



Абдуллина Квра Якуп кызы.

10 Ноябрь 1940 ел

Саба районы Явлаштау авылы

Белеме 4 класс

“Әти сугышка киткәнен хәтерләмим бик бәләкәй идем. Әтинең кайтканын хәтерлим. Сугыштан кайтканда башта Явлаштауга әби янына кайтты, аннан авылга. Мин каршына бардым. Без участкада тора идек, әтиләр берәр җирдә туктап торганнардырмы- әнине чакырган. Әни әти янына киткәч, безнең бар әйберне урлап чыкканнар. Әни әйтә торган иде: “Урлаган хатыннар минем тәрәзә пәрдәләреннән күлмәк тегеп киеп йөрделәр”,- дип. Без гаиләдә 4 бала үстек, мин олысы идем. Әти сугыштан кайткач та лесник булып эшләде. Аннары әтине Саба кардонына җибәрделәр. 1951 нче елдан Сабабашта тора башладык. Участкада 10 ел эшләдем, 1954 нче елдан 32 ел колхозда сыер саудым.”



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кукмара  урамы 18 нче йортта яши



Абдуллина Сөембикә Абдулла кызы

25 Октябрь 1936 ел

Саба районы Сабабаш авылы

“Сугыш башланганда кардонда калдым. Әти лесник булып эшли иде. Әти киткәнен ачык хәтерләмим, әни белән суга барганда туптан аткан тавышлар ишетелә иде. Без 4 бала идек. Әти 1946 нчы елны сугыштан кайтты, аннары лесник булып Саба кардонына китте. Мин икенче бала идем, әни урманчылыкта эшләде. Мишәбашка урман кисәргә китә иде, атнага бер генә кайтты. Әтинең әнисе - әби белән тордык. Әби алабуталар, яфраклар җыеп ашарга пешерә иде. Алдан Шәрип абыйлар кайтты. Сугыштан кешеләр кайткач, без дә бара идек. Алар балаларга карандаш, ручка,дәфтәрләр өләшә иделәр. Минем әти кергән балаларга ручка бирде. Әти Саба кардонына лесник булып киткәч, Сабага көн саен җәяү йөреп укыдык.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 65 нче йортта яши





Миннахметова Мәдинә Миннәхмәт кызы

22 август 1934 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 3 класс

“Мин гаиләдә өченче (төпчек) бала булып дөньяга килдем. Өскә кияргә кием булмады. Хәерчелек булгач, укырга йөри алмадым. 1941 елда сугыш башланганда, миңа 7 яшь иде . Кечкенә генә булсам да, бик күп авырлыклар күрергә туры килде.Фермада бозаулар карадым. Бер кешегә 24 бозауны карыйсы иде, 8 ел шунда эшләдем. Малларның ашарларына юк иде. Басудан бозауларга салам ташып ашаттык. Үскәч, 24 бозауны сабага куып алып барып тапшыра идек. Ул бозаулар корчаңгы авыруы белән авырый иде. Аларны кыра –кыра юа идек. Сирәк кенә кичке уеннарга чыккаладык.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 11 нче йортта яши





Миннекаева Роза Корбан кызы

07 сентябрь 1936 ел

Саба районы Яңа Җөри авылында туган

Белеме 4 класс.

“ Кызамык чыкты да укый алмадым. Гаиләдә 7 бала үстек, өчебез сугышка кадәр туды . 1943 нче елда әти сугыштан яраланып кайтты. Сеңлем белән әтинең каршына бардык. Ләкин әтине таба алмадык. Без өйгә кайтканда әти кайткан иде инде.Басудан черек бәрәңгеләр ташый идек. Бакчадан алган бәрәңгене дә чокырга күмеп куйган булганнардыр инде. Әнинең: “Әтиегез кайта, бәрәңге кирәк”,- дип , балта белән балчык чапканнары истә калган.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 47 нче йортта яши





Гараева Раушания Әхмәт кызы

03 ноябрь 1937

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 7 класс

“Башта колхозда сушилкада, аннары әртилдә, аннары бер ел Чепия районы (хәзерге Балтач районы) артилендә тегүче булып , аннан соң Сабабаш лесничествосында эшләдем. 7 нче классны Килдебәк мәктәбендә тәмамладым. 8 нче классны Сабага барып укырга кирәк иде. Көн саен җәяүләп барып кайтырга кирәк . Аякка кияргә юк, күтәртмә аяк киеме ясап йөреп карадым да пычрак вакытлар җиткәч, укуны ташладым. Язарга карандаш юк иде. Әремгә карандаш очы кидертеп яза идек.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 16 нчы йортта яши





Газизянова Миннезөхрә Гомәр кызы

26 январь 1942 ел

Кукмара районы Каенсар авылында туган

Белеме 7 класс

“ Әти сугышта үлеп калды. Әни, икенче кешегә кияүгә чыгып , Кемерово шәһәренә киттек. Миңа 5 яшь чакта, икенче бәбиен тапканда, әнием үлеп китте. Мине әнинең абыйлары үстерде. Аларның үзләренең балалары юк иде. Абый сугыштан яраланып кайткан.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 71 нче йортта яши





Мулласалихова Зөлфирә Касыйм кызы

07 март 1940

Сабабаш авылы

Белеме 7 класс

“Әти сугышта үлде. 3 бала үстек. Самолетлар очканда, әтине алып кайт, дип кала идек. Абыйлар белән, уфаллага төяп, печәннәр ташый идек. Камыл чабып, шуларны төяп алып кайта идек. Абыйлар булгач, авырлыклар бик эләкмәде дисәм дә була. Җизни сугыштан исән кайтты. Аның алдына утыртып сөйгәнен хәтерлим. Безнең этиләр 4 малай булганнар, 4 се дә сугышка китеп кире әйләнеп кайта алмаганнар. Әби ничек чыдады икән, дип хәзер дә уйлап йөрим.  Хәзерге тормышлар бик рәхәт бит. Мин гомерем буе фермада сыер саудым . Кул белән 24 тәр сыер сава идек.”



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 58 нче йортта яши



Мулласалихов Раиф Мулласалих улы

4 август 1937 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 7 класс

“1943 нче елда әти сугыштан яраланып кайтты, яше дә чыккан иде инде . Гаиләдә 6 бала идек 1924 нче елгы абый сугышта үлде. Мин 5 нче бала идем. Әни, үлгәнче, гомере буе абыйның кайтуын көтте. Үзем лесничествода эшләдем.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы  58 нче йортта яши





Яруллина Нурзидә Нуриәхмәт кызы

10 Сентябрь 1937 ел

Теләче районы Кече Кибәхуҗа авылы

Белеме 7 класс

“Без гаиләдә 5 бала идек. Мин, олы бала буларак, әни囊эштә чакта кечкенә энемнәрне- сеңлемнәрне карау минем өскә төшә иде Әни, һәрберебезгә бүлеп, бәрәңгене ястык астына тыгып китәр иде. Әни эштән кайтканда, каршысына йөгереп чыга идем. Әни: “ Бәрәңгеләрне Галиәхмәт ашап бетерде”,- ди. Ул энем яшьли үлеп китте. Хәзер уйлап йөрим: ярый ашатканмын әле, дип хатирәләрен яңартты Нурзидә апа. 1943 нче елны әтине (яхшы хезмәт иткәне өченме икән) кунакка кайтардылар. Мин ул вакытта әнинең апаларында кунакта идем. Шунда әтинең, килеп кереп, мине кочаклап алганы бүген дә хәтеремдә.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 40 нчы йортта яши





Набиуллин Васил Сафа улы

01 июль 1934

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 4 класс

“Гаиләдә 6 бала идек, өчебез сугышка кадәр туган. Мин иң олысы идем. Сәрдә өстендә кардонда тордык. Әтине сугышка Сабага озата бардык. Хәзерге универмаг урынында клуб иде. Кичкә кадәр тордык, аннары без кайтып киттек, алар калды. 1941 нче елның декабрь аенда авылга күчтек. Әтидән “хәбәрсез югалган” дигән хәбәр килгән иде. Әни ахыргы тавыкны суеп аш уздырды. Август аенда әтидән открытка килеп төште. “Адресыбыз үзгәрә, хат язмый торыгыз”,- дип. Әти пленда булган. Аннары шуннан шахтага җибәргәннәр. 1956 нчы елга кадәр эшләсәң, расчет бирәбез, дигәннәр . 1946 нчы елда отпускага кайтты. “1-2 ел эшлим дә, бәлки, расчет бирерләр”,- дигән иде. Әни: “Мин башка үзем генә калмыйм”,- дип ияреп киттек. 1960 нчы елга кадәр шунда эшләдем. Аннары Карагандага киттем, 32 ел шахтада эшләдем. 1981 нче елны пенсиягә чыккач та 9 ел эшләдем.”



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Карл Маркс урамы 5 нче йортта яши



Набиуллина Җүәйрә Шәймәрдан кызы

15 май 1935 ел

Саба районы Сабабаш авылында туган

Белеме 8 класс

“Гаиләдә 4 бала идек. Мин өченче бала идем . Кичке сәгать 4 тә радиодан “Сугыш башланды” дигән хәбәр килде. 4 нче көнне әтине сугышка алып киттеләр. Зиратка кадәр әтине озатып бардык. Әти Литвада сержант булып хезмәт итте. 1946 елда кайтты. Әти, сугыш беткәч, безгә сохарилар, шикәрләр җибәрде. Кайтканда брезин палата алып кайтты. Шуннан костюм тегеп кидем. Шул кастюмны кунакка йөргәндә бөтен кеше алып торды.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Карл Маркс урамы 5 нче йортта яши





Шакурова Сания  Тимергали кызы

15 Сентябрь 1941 ел

Саба районы Лесхоз бистәсендә туган

Белеме 7 класс

“Гаиләдә 3 кыз идек. Әтине бөтенләй хәтерләмим, ул сугышка киткәндә бик кечкенә идем. Әти кайтмады, сугыш кырында ятып калды. Өйдә әти дә, абый да булмагач, безгә бик авырга туры килде. Урманнан печән ташып мал асрый идек тә итен ашый алмыйбыз, тапшырырга кирәк иде. Черек бәрәңгеләр җыеп, шуннан крахмал ясап, ипи пешереп ашый идек. Ул вакытта бәрәңге нишләп чергәндер инде ул. Бик күп була иде черек бәрәңге.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар  урамы 30 нчы йортта яши





Хасбиева Физинә Бурхай кызы

2 октябрь 1937 ел

Башкортстан республикасы Янаул районы Ахтиял авылында туган.

Белеме 7 класс.

“Әти сугышка китте. Әти белән мин дә китәм, дип еладым, күпердән чыккач, әти мине аттан төшереп калдырды. Без гаиләдә 8 бала идек. 5 се сугышка кадәр туган. Мин 4 нче бала идем. Элек хәер сорашучылар йөри иде. Әниләр шулардан куркыптыр инде, безне түбән өйгә салып китәләр иде. Сугыш барган чорда безнең икебезне бабайлар алып китте. Без әни янында калдык. Әти сугыштан чирләп кайтты. Сугыш беткәнен хәтерлим. Бөтен балалар җыелышып урамга чыктык. Көтү кайткан вакыт иде.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Карл Маркс урамы 13 нче йортта яши





Яруллин Нотфулла Ярулла улы

07 июль 1935

Саба районы Сабабаш авылы.

Белеме 7 класс

«Сугыш башлану турында хәбәрне кырда ишеттек. Әтием сугышка 1942 нче елның февралендә китте . Хушлашыр минутлар җиткәч, әткәй кочагына алып сөйде . Кысып –кысып кочаклады. Шул вакытта миңа бөтен җиһан елыйдыр кебек тоелды. Күзләре уйчан , ә карашы назлы иде . Бу күрешүбез соңгы тапкырдыр, дип уйлап карамаганмын. Әткәй киткәннән соң, бөтен эш әнием һәм миңа калды. Алабута , башка төрле үләннәр ,черек бәрәңгедән пешерелгән ашлар төп ризык булды . Кырга әниләргә ярдәм итәргә бардык,мал-туарны да карадым, бер генә буш вакыт та булмады . Әниләр көнне-төнгә ялгап “Барысы да Җиңү өчен !”дип эшләделәр.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 40 нчы йортта яши





Ахметвалиев Фарил Әхмәтвәли улы

20 март 1935 ел.

Саба районы Сабабаш авылында туган.

Белеме 7 класс.

“1940 нчы елны әнием үлеп китте. Гаиләдә 5 бала калдык , иң кечкенә энем 3 айлык иде. Әнинең сеңлесе кияүдә иде, шул үзләренең күршеләрендә яшәүче бер баласыз гаилә белән сөйләшеп, энемне шуларга бирделәр. Әти гражданнар сугышыннан гарипләнеп кайтты. Яше дә олы иде, шуның өчен Бөек Ватан сугышына алмадылар. Башта бер хатынга өйләнде, аның белән ике ел яшәделәр. Безне бик каккач аерылды.1947 нче елда яңадан өйләнде һәм шул әни белән гомер иттек. Ул әнинең үзенең балалары булмады. Апа урман кисәргә чыгып китте дә шуннан кайтмады читтә төпләнеп калды.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар  урамы 38 нче йортта яши



“Баш иябез
Бөек елларга”



Ахметвалиева Венера Галиислам кызы

21.07.1940 белеме 7 класс

Саба районы Иске Мичән авылында туган

Белеме 4 класс

“Гаиләдә ике бала идек. Әти сугышта үлеп калды. Смоленск янында үлгән булып чыкты, интернет челтәреннән эзләп таптык. Әтинең бер килгән хаты әле дә саклана, гарәп хәрефләре белән язылган, үзебез укый алмадык. Кат-кат укып, бик нык таушалган, гарәпчә укый белүчеләр дә укый алмады. Әнинең укыганнары истә калган: “Сары чәчле Газиз улыма, үпкәчел Венера кызыма “,-дип язган иде. Сугыш беткәч, күрше кызымның әтисе кайтты, мин дә аны күрергә кердем, миңа 1 прәнник биреп чыгардылар. И куанган идем шул чакта.

Аннары әни әтине бик усал, кырыс кеше иде дип сөйли иде. Әтинең үлгән дигән хәбәре килгәч, әнидән сораган идем. – Әни, әтине бик усал кеше дип әйтә иден бит, ничек үтергәннәр соң аны?- дип. “ И кызым ,йоклаган чакта үтергәннәрдер инде”,- диде шунда әни. Башта сарык фермасында эшләдем. Аннары читкә китәсе килеп, абыйларга ияреп, Иркутск якларына чыгып киттем. Анда фермада сыер саудым. Үз районыбызда яшәүче Фарил бабагыз белән менә шунда таныштым да инде, дип тыйнак кына көлеп куйды Венера апабыз.”



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 38 нче йортта яши



Шарифуллина Алфинур Шарифулла кызы

10 март 1939 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 7 класс

“Әти сугышка киткәндә, бик бәләкәй идем. Сугыш беткән чакны бик яхшы хәтерлим, хатыннар мәктәпкә җыелды. Ирләре сугыштан кайтканнар сикерә-сикерә биеде. Безнең әни елап кайтты. Чөнки минем әтием сугыштан кайтмады. Басуда башак җыя идек. Шуны җыеп тапшырганга, бәләкәй генә кисәк ипи бирәләр иде. Тагын бер хатирә истә калган: иптәш кызымның әтисе кайткач, мәктәпкә килде дә кызын чакырып чыгарды. Шунда мин дә: Туктагыз, карыйм әле, әти нинди була ул?- дип йөгереп чыктым.

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативная урамы 43 нче йортта яши





Сабирҗанова Нәҗия Шәрип кызы

18 август 1937 ел

Саба районы Сабабаш авылында туган.

Белеме 7 класс .

“Әти сугышка төнлә чыгып китте. 3 бала ятып калдык. Уртанчы бала идем. Әби бар иде, шуңа булыша идем. Бала караштым, мин уртанчысы идем. 1946 нчы елның көзендә әти кайтты. Әти кайта, дип көткәнем хәтердә. Сугыш чорында ач булдык, ялангач булдык. Әни колхозда эшләде. Берәр атна кайтмыйча эшләгән вакытлары була иде.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативная урамы 41 нче йортта яши





Исхаков Әюп Исмәгыйль улы

10 август 1939 ел

Саба районы Сабабаш авылында туган

Белеме 4 класс.

“Әтинең бер дә фотосурәте сакланмаган .Мин аны хәтерләмим  дә ,кая инде, сугыш башланганда, миңа нибары ике яшь булган бит. Әтиләрне кырдан дәшеп алганнар, әни ашарга әзерләп йөргән вакыты булган. “Син аяк астында  буталып, комачаулап йөри идең”,-дип искә ала иде, әни минем хакта. 4 нче классны тәмамлаганнан соң, көтү көтәргә киттем. Аннары күп еллар урман тракторында эшләдем.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативная  урамы 18 нче йортта яши






Миннеханов Хадис Миннехан улы

5 январь 1937 ел

Саба районы Сабабаш авылы.

Белеме 7 класс

“Гаиләдә 4 бала идек. Мин 3 нче бала идем. Әти сугышта үлеп калды . Әтинең киткәндә әнинең итәгенә тотынып басып торганны хәтерлим. Сугыш беткән чакны әз генә хәтерлим, авыл уртасында күпер кырыендарак трибуна шикелле әйбер бар иде. Халык ни булса да шунда җыелды. Сугыш беткәч тә халык шунда җыелды. Авырлыкларны күп күрдек ,басуда башак җыя идек.”



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативная урамы 59 нчы йортта яши



Ибрагимова Мөсәвия Газизҗан кызы

18 Сентябрь 1939 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 7 класс

«Гаиләдә 5 бала үстек, мин 4 нче бала идем. Әтнең сугышка киткәндә кысып кочаклап : “Мин кайтканчы зур үс ,балам . Без җиңеп кайтырбыз!”- дигән сүзләрен искә алганда күзләремә яшь тула иде .Сугыш илгә күп хәсрәт, күз яше алып килде .Сугышка ир-егетләрнең яше дә , карты да китте.Тылда калган халыкның да тормышы җиңел булмады, ирләр эшен хатын-кызлар, балалар башкарды. Әти сугыштан исән кайтты.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 56 нчы йортта яши





Шарифуллина Афзалниса Юсуп кызы

20 август 1936 ел


Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 7 класс

“ Гаиләдә 4 бала үстек, мин 2 нче бала идем. Әти сугышка китте. Ленинградта үлеп калды. Башта సослангирда булды. Әни әтинең хәлен белергә барды. Анда аларны бик каһәрләгәннәр. Әни колхозда эшли иде. Кайткач, кич белән яфраклардан, кычытканнан безгә ашарга пешереп калдыра иде. “Сугыш бетте” дигән хәбәрне ишеткәнемне хәтерлим.”



Әтием Юсуп



Лидия сеңлем минем балачак
истәлекләрем исемдә төсле бит.
Мәктәптә укыганда китап дәфтәр-
ләребез булмады. классыбызга, кулларымга
калган 6 китап иде шуны чиратлашып
өйгә укырга, алып кайта идек.
Ачык бит язарга да кара савытына
манчып яза идек, манчырга кара бет-
сә, [illegible] күрмәгән кебек иде.
карасы булмаган балаларга, манч-
тыра иде. [illegible] утып табучыдан
исем бирделәр. аякларда чабата иде
су үтмәсен [illegible] да була иде
аннан соң карлар беткәч [illegible]
басуына черек бәрәңге җыярга чыга
идек, шул бәрәңгедән, үзе кора иде, тара
[illegible] тора иде аппак булып әнием
аннан кумач ~~[illegible]~~ пешерә иде. шуны
яратып ашый идек. басуда балалар
күп була иде. ихтирам белән
Афзалниса әбиең 1916 ел 29 январь



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 62 нче йортта яши



Шарифуллин Рәҗәп Шарифулла улы

12 август 1941 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 5 класс.

“Әти сугышка киткәндә, 5 көнлек булганмын. Әти сугышка киткәндә, тыкырыктан менгәндә, бер карт әйткән. “Улың Рәҗәп аенда туды, “Рәҗәп” дип кушарсың инде дигән. Бераздан әтидән хат килеп төшкән малайга. “Рәҗәп” дип куш дип. Гаиләдә 6 бала булганбыз, мин төпчеге идем. Әни эштә булды. Бәрәңгене казый идек тә Шәмәрдәнгә алып менеп тапшыра идек. Түбән өйгә төшкәч, бер бәрәңге таптым да абыйга: “Пешереп ашат әле?!”- дип бирдем. Абый кәстерүлгә күп итеп су салган да бәрәңгене пешерергә куйган. Суы беткәнче кайнаткач, бәрәңге дә изелеп юкка чыккан. Абыйдан бәрәңге таптырганны хәтерлим. Кычыткан, алабута ашап үстек. Әни сәгать 3-4 тә чыгып китә иде, обедка 25 сутыйлык норманы үтәп кайта иде. Көтү куарга калса, бригадирлар килеп куа башлый иде.”



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 62 нче йортта яши



Галиев Хатип Фатих улы

28 сентября 1939

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 7 класс

“Әти сугышта үлде. 4 нче класстан көтү көттем. 3 ц икмәк бирәләр иде. Көтүдә 48 сыер, 100 сарык, 30 кәҗә. Ике кеше көттек . Башта колхозда 3 ел почта йөрттем. Аннары фермада бозаулар карадым. 1967 елдан Леспромхозда эшли башладым. КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советының 1988 ел карары нигезендә СССР дәүләт премиясе белән бүләкләндем.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кукмара урамы 5 нче йортта яши





Галимов Мөхәммәтфәрит
Галим улы

04 гыйнвар 1937 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 9 класс

“Әти өч сугышта булган. Бөек Ватан сугышына 43 яшьтә киткән. Миңа ул вакытта 5 яшь иде. Әти сугыштан бер кулсыз кайтты. Каршы алырга бардым. Шунда әтидән сорадым: “Әти, кулың кайда?- дип. - Калды шунда”,- дип җавап бирде. Без гаиләдә 3 бала идек. Мин 3 нче бала идем. Авылда ярыш артиле бар иде. Әти шунда председатель булып эшләде. Үзебезнең үгез бар иде. Әти шуны җигеп көлтә ташыды , каплар суктыра иде, шуларны Шәмәрдәнгә тапшыра идек.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кукмара урамы 7 нче йортта яши





Рахмиева Гашура Каюм кызы

8 Февраль 1941 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 3 класс

“Әти сугышта хәбәрсез югалды. Әни әтине гомер буе көтеп йөрде. Әтинең хәбәрсез югалганлыгы турында бер хәбәр дә килмәде. Басудан черек бәрәңге, кычыткан җыя идек, авылда беткәч, урманга менә идек. Торырга өебез бетте. Гаиләдә 2 бала идек, мин икенчесе идем, абый белән Килдебәктәге бабай өй эшләде. 1956 елдан 2010 елга кадәр лесничествода эшләдем.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Тукай урамы 1 нче йортта яши





Газизянова Мәрям Зариф кызы

6 Гыйнвар 1937 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 3 класс

“Әти сугышта булмады авыру иде. Гаиләдә 4 бала идек. Мин 3 нче бала идем. Колхозда 15 яшьтән эшли башладым. Басуда урак урдым, печән чаптым. Өлкән апалар белән беррәттән чабарга кирәк . Көч җитми иде. Кайберләре кызгана , кайсылары: “Көчегез җитмәгәч килмәскә иде”,- дип ачулана иде. Хәзерге тормышыбыз бик рәхәт, аллага шөкер. Инде моннан соң сугыш афәтен беркемгә дә күрергә язмасын иде.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Тукай урамы 5 нче йортта яши





Билалова Фәния Солтангәрәй кызы

15 апрель 1938 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 8 класс

“Минем балачак авыр сугыш елларына туры килде, шулай да тырышып укып, 7 классны мактау грамотасына тәмамладым. Ләкин укуны дәвам итәргә мөмкинлек булмады. Комсомол путевкасы белән терлекчелеккә эшкә килдем. Кичке мәктәптә укып, 8 классны тәмамладым. 20 ел тавык фермасында эшләдем. 2 тапкыр район һәм авыл советына депутат булып сайландым. 1970 елларда Казанга комсомолның өлкә конференциясенә делегат булып сайландым, бу яшьлекнең бик күңелле мизгелләре булды. 1973 нче елда район кош караучылары арасында 1 урынга чыгып, дәүләтнең югары бүләге “Хезмәт кызыл байрак” ордены белән бүләкләндем. Ленинның тууына 100 ел тулуга чыгарылган юбилей медале , “Хезмәт ветераны” медале белән бүләкләндем. Аннан соң 20 ел сыер савып, 1993 елда “Атказанган колхозчы” исеме белән лаеклы ялга чыктым.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Лесная урамы 7 нче йортта яши





Сәләхиева Гөлзәйнәп Иляс кызы

8 Ноябрь 1940 ел

Саба районы Сабабаш авылында туган.

Белеме 4 класс

“Безнең балалык еллары дәһшәтле Ватан сугышына туры килде. Сугыш елларында ач-ялангач, черек бәрәңге, кычыткан ашап үстердек. Бар эшләрдә кул көче белән иде. Басуда ашлыкларны урак белән ура идек. Ашлыкны ат белән лабогрейка белән суктыра идек. Бар эшләрне дә хатын кызлар башкарды. Бөтен ир-атлар сугышка  киттеләр. Урман кисү, окоп казу, вагоннар төяү, чәчү орлыкларын станциядән чана белән тартып алып кайтулар. Бу эшләр хатын-кыз җилкәсендә иде.Ашарга черек бәрәңге кырып ипи пешерә идек. Өскә бер киндердән тегелгән күлмәк - ыштан иде. Аякта чабата иде. Яз – көз айларында аякка су кермәсен өчен, чабатага агачтан эшләнгән күтәртмә тага идек. Хәзерге тормыш матур да, мул да, тыныч та. Алга таба барыбызга да исән-сау,  тыныч тормышта яшәргә язсын. Без күргән михнәтле сугыш елларын беркемгә дә күрергә язмасын.”



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Мирная урамы 17 нче йортта яши



Касимова Мөсәлия  Төхбәт кызы

19 май 1936 ел

Башкортснан республикасы  Мешкә районы Карашев авылы

Белеме 7 класс


“Бөек Ватан сугышы башланганда 5 яшь иде. Әти Төхбәтулла сугышка китә. Шул китүдән туган авылына 2 елдан контузия алып кайта. Гаиләдә 5 бала идек :өч кыз, ике малай.  Тамак туйдырыр өчен, кешеләргә өйләр юдык, бәрәңге чүпләре утадык. 14яшьтә колхоз эшенә чыга башладык. 7 класс белем алгач, языылып, читкә эшкә киттек. Урман кистек, урак урдык, җир казыдык, тимер юлда рельслар салдык. Тормыш иптәшем белән шунда таныштык. Бераз очрашып йөргәч, акча эшли башлагач, тормыш иптәшем : “Әйдә безнең авылга кайтыйк, авыл уртасында зур күл бар, анда аккошлар йөзеп йөри, безнең авыл бик матур”, – диде. Авылга кайткач,  матур итеп яшәп киттек. Бер-бер артлы 4 бала таптык. Кайда гына эшләсәм дә, исемем мактау тактасыннан төшмәде. Мактау кәгазьләре, рәхмәт хатлары, медальләрем күп. “



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Тукай  урамы 4 нче йортта яши



Хәертдинов Кашафетдин
Хайрутдинович

04 гыйнвар 1939 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме югары

“Гаиләдә бер бала. Әти сугышка киткән. Сугыштан Үзбәкстанга кайткан. Аннары әни белән мин дә Үзбәкстанга киттем. Шунда укыдым, югары белем алдым.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Лесная урамы 11 нче йортта яши





Шафигуллин Ришат Шәфигулла улы

29 ноябрь 1936 ел

Саба районы Сабабаш авылында туган

Белеме 10 класс

“Әти карт иде, сугышка алмадылар. Без гаиләдә 10 бала идек, 3 абый сугышта үлде. 1945 нче елның 5 нче маенда әни үлде. Әни малайларымның үлгәнен ишеттем. “Сугыш беткән” дигән хәбәрне дә ишетсәм иде, дигән иде, 4 көн калгач үлеп китте. 1 ел әнисез яшәдек, аннары әти өйләнде, мин шулар белән үстем. “Сугыш беткән” дигән хәбәрне ишеткәнемне хәтерлим. Безгә кодача тиешле Мөсәвәрә апа бар иде, аның ярыш артиленә флаг алып килеп кадаганын хәтерлим. Авылда башка кеше булмагач, әтине председатель итеп куйдылар. Әти 2 ел председатель булып эшләде.”



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Лесная урамы 3 нче йортта яши



Сабирзянова Миннесәвия Юсуповна

28 гыйнвар 1936 ел

Кукмара районы

“Сугышның афәтен, авырлыкларын миңа сөйләгән, үземә иң кадерле кеше булган әбием турында язмасам гөнаһ булыр иде. Зәйнуллина Сәгъдәтбикә- аңа 3 яшь булганда, сугыш башланып китә. Әтисен сугышка алалар, шуңа да әбием әтисенең йөзен хәтерләми. “Иң зур хыялым- әтиемне күрү, рәсемен булса да!”- диеп әйтә әбием. Ашарга ризык булмый. “ Бервакыт әни үләннәрдән аш пешерде, инде ничә көннәр буе ачлы-туклы яшәгәнгә, бик ашыйсым килде, үзем эле кечкенәмен, ашыйм дип өстәлдәге бар гаиләгә дигән ашны түктем,”-уфтанып сөйләде әбием. Мәктәптә белем алу тәтеми, инде балачагыннан ук олылар белән эшкә чыгарга туры килә. Бу авырлыкларга түзгән, алдагы тормышын тыныч булыр дип өмет иткән. Балачакның иң күңелле вакытларында колхоз кырында урак урырга туры килә. Шуңа күрә хәзерге көнгә әбием шөкер ана кылып яши, алар кичергән кайгыларны беркайчанда күрергә язмасын дип, догалар укый.”

Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативная  урамы 37 нче йортта яши





Миннехадиева Шәмсенахар Мингазетдиновна

3 декабрь1938

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 4 класс

“Гаиләдә 4 бала үстек: 3 кыз 1 малай үстек. Сугыш вакытында кул пычкысы белэн урман кистем, 3 ел комбайн ярдэмчесе булып эшләдем , аннары гомерем буе фермада сыер саудым. 25 сыерны кул белән сава идек. Сугыш вакытында бик авырга туры килде, авыл халкы белән басудан черек бәрәңгелэр , кычыткан ашадык.”



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Мирная урамы 15 нче йортта яши



Зарипов Раис Галимзянович

7 декабрь 1941

Сарман районы (Хәзер Тукай) районы Күктәк Мирсәет авылы.

Белеме махсус урта

“Менә шундый таңнарның берсе -1941 нче ел 22нче июнь. Якшәмбе көн. Кояш чыгарга иртәрәк әле. Кешеләр тыныч йокыда. Бөтен табигать сихри тынлыкка чумган. Кайдадыр еракта чут-чут итеп сандугач сайравы гына ишетелә. Шушы тынлыкны бозып, кинәт көнбатыштан самолетлар гөрелтесе ишетелә. Шомлы үкерү тавышы көчәйгәннән-көчәя бара, кешеләр ни булганын аңлап бетергәнче йөзләгән, меңләгән хәрби самолетлар тыныч шәһәрләр һәм авыллар өстенә бомбалар яудыра башлый. Күпкатлы йортлар гөрселдәп авалар, күккә тузан болыты күтәрелә, коточкыч янгын башлана. Дөньяның асты- өскә килгәндәй була. Урамнарда, юлда очраган бөтен нәрсәне вата-сыта килүче свастикалы танклар, бала-чаганың, аналарның ачынып елаган тавышлары, кан, үлем. Бөек Ватан сугышы менә шулай башлана. Һәркем өчен дә авыр сынау еллары башланып китә.”



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Лесная урамы 6 нчы йортта яши



Зарипова Флера Файзрахмановна

3 май 1939 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 7 класс

“Гаиләдә 4 бала идек. Мин төпчеге идем. 6 яшьтән әнигә иптәшкә урманда охранник булып тордым. Умарта саклaдык , әти сугышка китте. Туганнарым эшкә киткәч,  мин әнигә иптәшкә кала идем. Әни урманда үзем генә торырга куркам ,дип эштән китәргә гариза язды. Эшләргә кеше юк, дип җибәрмәделәр. Әти хәбәрсез югалды. Гомер буе әти кайтмасмы дип яшәдек.  Берүзем мәктәпкә укырга йөри идем, әни басуга кадәр урман эченнән караңгы вакытларда озата иде. Басуга чыккач, авылга җиткәнче йөгерә идем.  7 нче сыйныфны тәмамлагач ,Килдебәк мәктәбенә укырга төшкән идем. 1-2 ай укыдым да юл булмагач туктадым.



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Лесная  урамы 6 нчы йортта яши



Хабибрахманова Минсылу Миннемулла кызы

3 ноябрь 1940 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 7 класс

"Шөкер, илебезнең күге аяз.Сугыш турындагы кинофильмнарны караганда йөрәк сыкрый, күңел елый. Данлы еллар ерагайган саен, үткәннәрне онытмасак иде. Үткәннәрдән башка киләчәк юк. Әйдәгез, үзебезнең данлы үткәнебез белән горурланудан туктамыйк, ул чорның данлы улларына һәм кызларына ихтирамыбызны киметмик. Әмма шуңа җан әрни – сугышсыз да ятимнәр күбәя. Балаларга ана назы, ана тәрбиясе кирәк. Үзләре турында шундый ярату һәм тәрбия күргән балалар мәрхәмәтле, шәфкатьле, тыныч булып үсәрләр. Аларга ходай сабырлык бирер. Бәхәсләрне түгәрәк өстәл артында чишәрләр, сугышлар булмас. Яшәсен тынычлык!!!



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Тукай урамы 12 нче йортта яши



Муллахметов Муллагаян Муллахмәт улы

30 май 1926 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме

“Минем  кебек бик күпләр Ватан өчен үзләренең гомерләрен дә кызганмыйча, авыр сугышны җиңеп, дөньяны зур афәттән коткарып, туган илебез бәхетле тормышта яшәсен өчен үзебезнең көчебезне кызганмадык. Җиңүгә юл озын һәм авыр булды. Сугышчылар соңгы сулышка кадәр изге антларына тугры калдылар, намусларына тап төшермичә, азатлыкны буарга ирек бирмәдек һәм халкыбызны коллыктан саклап калдык.”



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Кооперативлар урамы 28 нче йортта яши

“Баш иябез Бөек елларга”



Новикова Насима Рамазановна

24 август 1940

Саба районы Сабабаш авылында туган

Белеме 7 класс

“Әти сугышка киткәнен хәтерләмим, бишектә калганмын. Сугыш вакытын белмим, сугыштан соң үземне белә-белгәннән бик авырлыкта үстем, азрак булса да ипи булыр, дип башак җыйдык, аны чиләк белән күтәреп амбарга тапшыра идек, безгә шуның өчен кечкенә генә кисәк ипи бирерләр иде. Җәй житүен түземсезлек белән көтә идек.Бакча яннарында үскән көпшә, балтырган, кәҗә сакалы, акбаш, песи борчагы дисеңме -берсе дә калмады.  Сугыш беткәч, әти кайта, дип повестка бирделәр. Әй, көтәбез әтине , бөтен күрше-тирә керде. Бу повестка Лесхозга булган, фамилиясе, исеме бер булган. Әти кайтмагач, мин бик елдадым.  Гомер буе көттем, әтине әле дә кайтып керер төсле. Әтисез балалар бик тилмереп үсте инде ул чорда.



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Карл Маркс урамы 15 нче йортта яши



Ханова Зәйтүнә Хадиевна

13 август 1936 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 7 класс

“Илләр, кешеләр язмышында мәңге онытылмаслык вакыйгалар аз түгел. Әнә шундый вакыйгаларның берсе булган Бөек Ватан сугышын, фашист илбасарларына каршы халкыбызның героик көрәшен бөтен Җир шары хәтердән мәңге җуймас. Кешелек тарихына иң күп канкойгыч сугыш булып кергән Бөек Ватан сугышында Җиңү армиябезгә, халкыбызга дан һәм шөһрәт китерә. Сугыш... Нинди авыр, каһәрле, шомлы сүз бу! Ул 27 миллион кешенең гомерен өзгән, күпме баланы ятим иткән, аналарны тол калдырган...Сугыш... Меңләгән шәһәрләр җимерелгән, Җир йөзеннән гөрләп торган авыллар юкка чыккан, шау чәчәккә күмелгән бакчалар янып көлгә әйләнгән.Бөек Ватан сугышында халыкның батырлыгы, Туган илгә бирелгәнлеге, чиксез мәхәббәте, төрле милләт халыкларының бердәмлеге күренде. Ил өчен авыр сынау көннәрендә халкыбыз бер йодрыкка тупланды. Фронт һәм тыл бердәм булды.Авылда картлар, хатын-кызлар һәм балалар гына калды. Ә тормышны алып барырга кирәк иде – игенне дә игәргә, балаларны да ач-ялангач итмәскә, сугышка җылы киемнәр дә әзерләп җибәрергә, бик күп салымнар да түләргә кирәк иде. Әмма тыл халкы сынатмады, сыгылмады.



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Тукай  урамы 2 нче йортта яши

“Баш иябез
Бөек елларга”




Ханов Рәшит Ханович

25 сентябрь 1935 ел

Саба районы Сабабаш авылы

Белеме 7 класс

“Мин 1935 нче елны тудым. Яшьтән ачлык күреп үстем.  Яфрак, кычыткан ашадык. Өйдән малларны алып чыгып киттеләр.  Кибетләрдә дә ашамлык, сату әйберләре  бөтенләй булмады. Киртәдән салынган өйне гел кар басты. Утын бирмәделәр,  кышкы салкынга түзәрлек булмаганга,  ягарга агач ботаклары, ашарга ризык эзләп үтә иде көн. Кечкенә генә булсам да, исемдә: Килдебәк авылына хәер сорашырга барган. Соранып йөрүчегә дә төрле кеше төрлечә карый, кемдер жәлләп, кызганып кала, тик бирерлек азыгы булмый, икенче берсе ачуланып куып чыгара. Йөри торгач,  Зәкия  апа ике бәрәңге биреп чыгарган иде.  Ул вакытта өскә кияргә киеме дә юк, ялангач урамда йөргәнне Зөһрә апа күреп алып кертте мине үз өенә, ул көнне шунда кундым.  Җәен борчак булса да ашарга, дип басуга бара идек малайлар блән. Аннан да каравылчы авылга кадәр куып кайта.”



Хәзерге вакытта Саба районы

Сабабаш авылы

Тукай  урамы 2 нче йортта яши